ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе таныклыгы үрнәген һәм тасвирламасын раслау турында

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе турында» 2026 елның 17 мартындагы 580-VII ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе турындагы нигезләмәнең 4 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе таныклыгы үрнәген һәм тасвирламасын расларга (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы

М.Г. Әхмәтов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ


Казан шәһәре
2026 елның 8 апреле
№ 161-VII ДСП

2026 елның 17 мартындагы
161-VII ДСП номерлы
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
Президиумы карарына
кушымта


**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының**
**Мактаулы Рәисе таныклыгы үрнәге һәм тасвирламасы**

1. Таныклык үрнәге:

а) таныклыкның тышлыгы:




б) таныклыкның эчке ягы:




2. Таныклык тасвирламасы:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе таныклыгы 95 х 65 мм зурлыкта куе кызыл төстәге күн тышлыклы кенәгә рәвешендә була.

Таныклыкның тышкы ягында алтынсу төстәге фольгада башкарылган Татарстан Республикасы Дәүләт гербының график сурәте һәм аның астында 15 зурлыктагы шрифтта баш хәрефләр белән икешәр юлга язылган «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ», «ГОСУДАРСТВЕННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» язмалары бастырыла.

Таныклыкның эчке сул ягында аның сул өлешендә Татарстан Республикасы Дәүләт гербының төсле сурәте урнаштырыла.

Таныклыкның эчке сул ягының калган өлешендә түбәндәге эчтәлекле текст бирелә:

өстә уртада – 8 зурлыктагы яртылаш калын шрифтта баш хәрефләр белән өч юлга «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНЫҢ МАКТАУЛЫ РӘИСЕ» язмасы;

аста уртада – 9 зурлыктагы яртылаш калын шрифтта баш хәрефләр белән ике юлга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мактаулы Рәисенең татар телендә фамилиясе, исеме, атасының исеме;

аста уртада – 9 зурлыктагы шрифтта баш хәрефләр белән «ТАНЫКЛЫК» язмасы;

аста уртада – 9 зурлыктагы шрифтта баш хәрефләр белән «УДОСТОВЕРЕНИЕ №» язмасы;

аста уртада – 8 зурлыктагы яртылаш калын шрифтта баш хәрефләр белән өч юлга «ПОЧЕТНЫЙ ПРЕДСЕДАТЕЛЬ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» язмасы;

аста уртада – 9 зурлыктагы яртылаш калын шрифтта баш хәрефләр белән ике юлга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мактаулы Рәисенең рус телендә фамилиясе, исеме, атасының исеме.

Таныклыкның эчке уң ягында уңда – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мактаулы Рәисенең 40 х 30 мм зурлыктагы төсле фоторәсеме, сулда Татарстан Республикасы Дәүләт флагының төсле сурәте урнаштырыла.

Таныклыкның эчке уң ягының калган өлешендә түбәндәге эчтәлекле текст бирелә:

аста сулда – 9 зурлыктагы курсив шрифтта юл хәрефләре белән ике юлга «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе» (яисә «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе вазыйфаларын башкаручы») язмасы;

аста сулда – 9 зурлыктагы курсив шрифтта юл хәрефләре белән ике юлга «Председатель Государственного Совета Республики Татарстан» (яисә «Исполняющий обязанности Председателя Государственного Совета Республики Татарстан») язмасы, уңда – 9 зурлыктагы курсив шрифтта юл хәрефләре белән ике юлга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе (яисә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе вазыйфаларын башкаручы) инициаллары һәм фамилиясе;

аста уртада – 8 зурлыктагы курсив шрифтта юл хәрефләре белән таныклыкның бирелү датасы.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе (яисә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе вазыйфаларын башкаручы) имзасы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе фоторәсеменең сулъяк аскы почмагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөһере белән таныклана.

Таныклыкның эчке якларына таныклык тышлыгы төсенә туры килә торган җирлек (тангир челтәр) ясала.

Таныклыкның эчке якларындагы язмалар кара төстә Times New Roman шрифтында югары сыйфатлы итеп бастыра торган принтерда башкарылырга тиеш.